**«2017 елга Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисапны раслау хакында» Зеленодольск муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча**

**бәяләмә**

Зеленодольск шәһәре 2018 елның 14 мае

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының «2017 елда Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турындагы хисапны раслау хакында «Зеленодольск муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында» 2018 елның 04 маендагы 84 номерлы карары ниезендә гавами тыңлаулар үткәрелде.

Халыкны таныштыру өчен 2017 елгы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисап Интернет челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырылды.

«2017 елгы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисапны раслау хакында» Зеленодольск муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру өчен кирәкле барлык процедуралар тиешенчә үтәлде.

2017 елгы Зеленодольск муниципаль районы бюджетының үтәлеше турында докладлар һәм хисап алышу барышында Зеленодольск муниципаль районында яшәүчеләрдән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр килмәде.

Зеленодольск муниципаль районы Советының «2017 елгы бюджет үтәлеше турында хисапны раслау хакында» карары проекты буенча гавами тыңлауларда катнашучылар аны хупладылар һәм раслауга тәкъдим иттеләр.

Җитәкченең беренче урынбасары С.В. Кадырова

«2017 елга Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисап раслау хакында» Зеленодольск муниципаль районы Советының карар проекты буенча гавами тыңлаулар беркетмәсе

Зеленодольск шәһәре 2018елның 14 мае

Ленин ур., 46 й. 16.00

А.М. Горький исемендәге мәдәният һәм халык иҗаты үзәге

**Рәислек итүче:**

**Кадыйрова Светлана Викторовна** - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары

Гавами тыңлаулар беркетмәсен алып бару өчентүбәндәге составта **секретариат** сайланды:

**Серякова Анастасия Сергеевна** - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-икътисадый фаразлау һәм анализлау бүлеге башлыгы.

**Нуриева Сания Абдулла кызы** - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-икътисадый фаразлау һәм анализлау бүлегенең баш белгече.

**Чыгыш ясаучылар:**

**1. Кадыйрова Светлана Викторовна** - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары « 2017 ел өчен Зеленодольск муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары турында» мәгълүмат бирде.

**2. Дёгтева Ольга Павловна** - «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МУ җитәкчесе 2017 елгыЗеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хәбәр итте.

**3. Сибгатуллина Лилия Наил кызы** - Зеленодольск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ мөлкәт белән идарә итү бүлеге башлыгы муниципаль милектәге мөлкәттән файдалану һәм икътисадның муниципаль секторын үстерү планының үтәлеше турында хәбәр итте.

Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының документлар белән тәэмин итү бүлегендә фикер алыша торган мәсьәлә буенча гражданнардан тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелмәде, чыгыш ясау хокукына гариза булмады.

Секретариатка хат килмәде.

Җитәкченең беренче урынбасары С.В. Кадыйрова